Чыганак: **Җиһаншина, Р.А. Күңелем түреннән: истәлекләр / Р.А. Җиһаншина.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.- 96 б. рәс. б-н.**

## АНА ХӘСРӘТЕ

Җиңүне күптән көтә идек. Ниһаять, ул көн килде. 9 нчы май көнне бөтен халык урамга — Ирек мәйданына агылды, җыр-гармун, елаш-сыкташ барысы да бергә бутала, кешеләр бер-берсе белән кочаклашып үбешәләр, тәрәзәләрдә патефон уйнаткан авазлар яңгырый.

Җиңү килде, ләкин күпләр әйләнеп кайтмадылар. Алар — Гыйльметдин Газизов, Бәкер Юсупов, Йосыф Сәгыйтов, Хәмит Хөсәенов, Фаикъ Камалов һәм башкалар... Исән-сау кайтучыларны колач җәеп каршыладык, алар иҗади эшкә чумдылар.

Сугыш беткән җәйдә июнь башларында без кайбер дуслар белән пароходта Агыйдел буйлап Уфага бара идек, Әҗәкүл пристанена тукталдык. Яр буенда аллыгөлле күлмәкләр кигән хатын-кызлар көнбагыш чиртәләр, егетләр гармун суза, халык мәш килә. Алар сугыштан кайтучыларны көтәләр. Ниһаять, пароходтан җиңеп кай-

тучы солдатлар чыга башлады. Кайсының кулында матур футлярга салынган аккордеон, кайсыдыр чемодан тоткан. Менә аркасына кечкенә генә капчык салган озын буйлы урта яшьләрдәге бер гаскәри чыгып килә. Ә яр башыннан өстендәге киндер күлмәкнең ертыгыннан аз гына тәне күренеп торган, ике кулы да терсәккә кадәр тирескә буялган (күрәсең, ул мичкә ягу өчен тирестән кирпеч суккан булгандыр, сугыш елларында аны бик күп сугалар иде) вакытсыз картая башлаган бер хатын чаба, ул: «Кайтты бит, кайтты бит!» — дип, йөрәк өзгеч итеп кычкыра, аның күзләре тирә-якны күрми иде...

Куллары пычрак булганга ул хәтта иренә кагылырга да курка, алар бер-берсенә озак карашып тордылар һәм ир кеше хатынның җилкәсенә кулын салган хәлдә яр башына менеп киттеләр.

Без, пароход палубасында бу хәлне күзәтеп торучылар, чыланган күзләребезне сөртәбез. Арабызда Таҗи Гыйззәт тә бар иде. «Мин бу күренешне һичшиксез язачакмын»,— дигән иде. Ах ул аналар, хатыннар, балалар сагышы! Алар әле бүген дә җанда авыр җәрәхәт булып торалар. Шушы сугыш елларының авыр хәсрәте безнең коллектив членнарына да кагылды, әлбәттә. Минем бу урында туктап, бер ана хәсрәтен кыскача гына булса да сөйләп үтәсем килә.

* * *

«Исәнме, әнием!

Менә икенче көн мин юлда, Казанда синең янында уздырган кыска гына вакыт — минем иң бәхетле көннәрем булды, гүя ул шатлыклы төш кенә иде.

Менә мин пароходта — юлда. Белмим, тагын кайчан да булса мин Казанга кайта алырмынмы? (Бер генә сәгатькә, хәтта минутка гына булса да.)

Идел өстендә салкын җил, әйтерсең лә ул безне пароходыбыз белән күтәреп, кире Казанга илтеп куярга ты-

рыша. Хәтта табигать тә безнең аерылышуга каршы килә. Пароход бик акрын бара, без Казаннан иртәнге 5 тә генә кузгалып киттек, мин төне буена йокламадым, һаман сине уйладым. Дөресен әйткәндә, сине машинага озата барганда миндә ике теләк туган иде: берсе — пароход кузгалып киткәнче синең белән бергә булу, икенчесе — тизрәк сине өйгә озату, чөнки син бик арыган идең, әнием! Сиңа үзеңне бик сакларга кирәк, синең йөрәгең сәламәт түгел бит. Әнием! Син борчылма, мин хатларны ешрак язарга тырышырмын. Иртәгә иртән Саратовка җитәрбез. Екатерина Васильевна һәм полковник Живлянукка сәлам әйт.

*Сәлам белән, үбеп синең улың Ф. Бакиров.*
*28.VI.43. «25 октября» пароходы».*

Бу юллар Фатыйма апа Ильскаяга язылганнар. Аның улы Фуат Бакиров Ватан сугышы башлануга армиягә алына һәм бер елдан артык Саратов шәһәренең 2 нче танк училищесында укып, кече лейтенант дәрәҗәсе ала. Сугышка китәр алдыннан Казанга кайта. Бу аларның соңгы очрашулары була.

Татар театры сәхнәсендә балкыган Фатыйма Ильская турында күп язмалар бар. Бу юлларны язарга мине аның зур йөрәкле ана булуы этәрде. Гомеренең соңгы көннәрендә миңа Фатыйма апа янында бик еш булырга туры килде. 1984 елның көзендә аның сәламәтлеге шактый какшаган иде, мин аның хәлен белергә көн дә өенә кереп йөрдем, чөнки аны ялгызын гына калдырырга ярамый иде. Бу эштә миңа артистка Хәлимә Искәндәрова теләктәшлек белдерде. Ноябрь башларында аның хәле авырая башлагач, яңадан больницага ятарга ризалык бирде һәм 5 нче ноябрь көнне без аны илтеп урнаштырдык. Хәлимә белән чиратлашып аның янында тәүлекләребезне уздырдык.

8 ноябрь иртәсендә мин тагын аның янына килдем. Ул сөтле чәй эчә-эчә миңа болай диде: «Әй, Рәшидә, бүген бит минем улымның үлгән көне, ул 1943 елның 8 ноябрендә сугыш кырында һәлак булды бит»,— диде. Мөлдерәмә

яшь тулы кара күзләре миңа туры карап торалар, гүя аның бөтен җаны, йөрәге улы белән сөйләшә иде. Шунда ул: «Әгәр Фуатым исән булса, ул да һәм аның балалары да минем янымда булырлар иде бит»,— дип, әрнеп-көрсенеп куйды. Ул көнне без бик озак Фуат турында сөйләштек. Фатыйма апаны юатырлык сүзләр эзләдем мин... Менә шул кичтәге сөйләшү минем күңелемә уелып калды һәм мин, кайчан да булса бу хакта кешеләргә сөйләрмен, дип үземә вәгъдә беркеттем.

15 нче ноябрь таңында Фатыйма апа вафат булды.

Ул ялгыз яшәде һәм, якыннары булмау сәбәпле, тиешле органнардан килгән вәкилләр аның фатирындагы әйберләрне исәпкә алдылар. Шул вакыт идәндә бер читтә саргаеп беткән газетага төрелгән кечкенә бер төргәкне күреп алдым, бу сугыш кырыннан аның улы язган хатлар иде. Комиссия әгъзалары моңа игътибар итмәделәр, аларны фәкать бәяле әйберләр генә кызыксындыра иде.

Менә шул хатларның берничәсен биредә китерәсем килә.

«Минем кадерле әнием!

Мин сиңа телеграмма белән үземнең Тула шәһәреннән берничә километр читтә икәнемне хәбәр иткән идем. Мин монда яңа машина алдым, син моның нинди зур бәхет икәнен аңлыйсыңмы? Үз машинаңның төзек булуын кайгырту, ул синең юлдашың икәнен аңлау, аны саклау һәм һәрвакыт карап тору кирәклеген аңлау — бик зур җаваплылык. Мин ул машинаны алгач, дүрт көн, дүрт төн аны карадым-тикшердем. Минем шулай эшләвемне күреп, бөтен подразделение зур энтузиазм белән эшләде. Мин һәрвакыт уйлыйм, алда торган каты сугышларда мин дошманга каршы тора алырмынмы, аны чигенергә мәҗбүр итәрменме? Тормышның шушы каты сынауларына мин чыдармынмы? Һәр чакта мин үземнең кыска гына тормыш биографиямә күз салып, училищеда алган командирлык белемнәремне, сугыш сабакларын искә алып, мин ышаныч

белән әйтәм: әйе, мин чыдармын бу сынауда. Мин җиңүче булып чыгармын, дим.

Әнием! Минем озак язмый торуыма ачуланма, мин яхшы, хәтта бик яхшы яшим, ашау яхшы. Мин һәр көнне сөт сатып алам.

Минем вакытлыча адресым: г. Тула, ст. Хомякова б/н 4.

*Сәлам белән сине кочаклап үбеп, улың Фуат. 24.8.1943».*

Ах бу ана йөрәге! Хат алу зур шатлык булса да, улының ут эченә керә баруы аны чиксез борчый. Ләкин Фатыйма апа сыгылып төшми, ул һаман да эштә, ул сыкранган күңелен иҗади эш белән баса, бу вакытларда ул берсеннән-берсе гүзәл сәхнә образлары иҗат итә һәм кичләрен тамашачылар алдына чыга: «Король Лир»да — Корделия, «Ромео һәм Джульетта»да — Джульетта, «Печән өстендәге эт» комедиясендә — Диана, «Чын мәхәббәт»тә — Гөләндәм һәм башкалар. Сәхнәдә тирән кичерешләр белән яши, тамашачыларның көчле алкышлары аңа көч һәм илһам бирә.

Фатыйма апа һәрвакыт кешеләр арасында булырга тырыша, урамнан узган яшь офицерлар аңа үз улы кебек күренә — аларга эндәшәсе килә аның.

Сугыш елларында тормыш җиңел булмады, ләкин Фатыйма апа һич тә көрсенмәде, зарланмады, коллектив членнары аңа ихтирам белән карадылар. Көннәр уза, кайчак ана йөрәге ярсып тибә, каядыр ашкына. Аның бер генә сәгатькә булса да улы янына барасы килә, берничә ай элек улының хатындагы: «Белмим, тагын Казанга кайта алырмынмы? (Бер генә сәгатькә, хәтта минутка булса да.)» дип язган сүзләр үзәген өзгәлиләр.

Ниһаять, Фуатның соңгы хаты.

«Исәнме, минем кадерле әнием! Бүген минем шатлыклы көнем, озак кына көткәннән соң синнән хат алдым һәм синең сау-сәламәт булуыңны һәм ялда булып кайтуыңны белеп шатландым. Берничә көн элек (алдан җибәргән 700 сумнан тыш) сиңа тагын 1350 сум акча җибәрдем, бер ун көннән соң тагын 2500 сум җибәрермен, зинһар өчен минем үтенечне үтә, үзеңә яхшы мех манто ал.

Мин сиңа озак кына язмый тордым, чөнки бик авыр, каты бәрелештә катнашырга туры килде — йа алла, мин ул сугыштан исән чыктым. Тагын биш көннән бәйрәм булачак һәм син дусларың белән бәйрәм тосты күтәргәндә мине дә искә алырсың дип уйлыйм.

Иртәгә яки берсекөнгә Украинаның зур шәһәрен алу өчен бик дәһшәтле сугыш булачак һәм мин ул сугышта да катнашачакмын, без анда бөтен көчне салачакбыз. Әгәр мин ул сугыштан исән чыксам — димәк, бу минем бәхетем, димәк, 20—25 ноябрьләрдә бер 10—15 көнгә өйгә ялга кайтачакмын. Хәзергә шуның белән хатны бетерәм. Сине кочаклап үбәм. Живлюкин гаиләсенә сәлам әйт.

*Тагын бер мәртәбә үбеп, улың Фуат.*

*2.XI.43 ел».*

Фатыйма апа, әлбәттә, улының теләген үтәде. Ул яхшы котик манто сатып алды һәм аны бүлмәсенең түрендә күз карасы кебек саклады.

Фуат Бакиров Киев шәһәрен алу өчен барган каты сугышта һәлак була. Бу соңгы хаттан соң Фатыйма апа ана йөрәген өзгәли торган олы хәсрәтне сөйли торган хәбәрләр ала.

Фуатның командиры — дусты лейтенант М. А. Лаптев хаты.

«Хөрмәтле иптәш Ильская!

Украина халкын немец фашистлары коллыгыннан азат итү өчен барган канлы сугышларда сезнең улыгыз Ф. Ба-

кировның һәлак булуын тирән кайгы белән белдерәм. Ул 43 елның 8 ноябрендә Фестов районы җирендә корбан булды. (Каберенең кайдалыгын соңрак хәбәр итәрмен.)

Бу безнең өчен бик зур югалту, ана йөрәге өчен — чын мәгънәсендә илебезнең патриоты, батыр йөрәкле улының һәлак булуы — тиңсез зур хәсрәт.

Бу юлларны язу миңа бик авыр, ләкин бу — минем бурычым.

Иптәш Бакиров белән без дуслар идек, ул һәрвакыт әнисен зур мәхәббәт һәм хөрмәт белән искә ала иде, әгәр сугыш кырында ятып калса, сезнең өчен ни дәрәҗәдә зур фаҗига буласын аңлый иде. Андый очракта ул миннән сезне юатуымны үтенде. Ләкин сезнең кайгыгызны җиңеләйтерлек, ана йөрәген тынычландырырлык сүзләрне каян табарга соң?

Мин фәкать шуны гына әйтә алам, сезнең улыгыз катнашкан дәһшәтле сугышта бик күп авыллар һәм меңләгән совет кешеләре фашист коллыгыннан азат ителде һәм йөзәрләгән фашист ерткычларын юк иттек, күпләрен пленга алдык.

Сезнең тирән кайгыгызны уртаклашабыз.

*М. А. Лаптев. 8.11.43 ел».*

Ул көн Фатыйма апа өчен дәһшәтле көн булды. Без аны ничек юатырга белмәдек, аның белән бергә күпләребезнең йөрәге сыкрады.

Ләкин олы йөрәкле ана үзендә көч тапты, ул көнне театрда «Гроза» («Яшенле яңгыр») спектакле барырга тиеш иде. Администрация спектакльне башка әсәр белән алмаштырырга уйлады, ләкин горур артистка Фатыйма Ильская бөтен көчен җыйнап: «Юк, алмаштырмагыз, мин уйныйм, минем бөтен тормышым сәхнә, кайгымны да аның белән уртаклашам»,— дип җавап бирде. Ул спектакльдә Катерина ролен башкара, соңгы пәрдәдә Борис белән саубуллашу сәхнәсен күз яшьләре белән уйнады, йөрәгендәге бөтен хәсрәтен сәхнәгә салды. Без — спектакльдә кат-

нашучылар — сәхнә артында аны күзәтеп түзә алмадык, яшьләребезгә тыгылдык... Спектакльдән соң аны озата бардык, ләкин ана йөрәген юатырлык бер генә әмәл дә тапмадык.

Соңрак аңа Фуатның дусларыннан, лейтенант Лаптевтан тагын хатлар килә, ул үзе дә аларга хатлар яза һәм улының каберен эзләтә, ниһаять, ул хәбәр дә килә.

Сугыш беткәннән соң Фатыйма апа улы каберенә бара, озак вакыт Фуатның исән калган дуслары белән хәбәрләшеп тора.

Йөрәк түрендәге сагыш аның иҗаты белән үрелеп яши.

«Тормыш җыры» спектаклендә Фатыйма хисләре аша тамашачыларны тетрәтә, ире Басыйрның үле хәбәрен алгач сөйли торган монологында «Юк, юк, Басыйрым, син үлмәдең, син исән», дигән сүзләрендә чиксез көчле сагыш һәм ышаныч яңгырый иде.

Соңрак ул гарәп язучысы С. Җамалның «Фатыйма Сабри» драмасында карт ана — Фатыйма образын башкарды. Бу рольдә Фатыйма апа Ильская ана сагышын тирән итеп бирә. Коммунист улы Фәрхәтне дошманга сатмас өчен, сорау алу вакытында улы белән күзгә-күз очраштыргач, бик тыныч кына: «Мин бу кешене белмим»,— дип җавап бирә. Ләкин аның беренче карашта үзен тыныч тоткан булып күренүе һәм тынычлык астында ташып торган хәсрәт авазы тамашачыларны тетрәтә иде. Фәкать зур сугыш кичергән аналар гына шундый тирән хисләрне бирә ала, әлбәттә.

Талантлы артистка сәхнәдә балкыган якты образлары белән халык йөрәгендә урын алды һәм ана буларак та ул тирән ихтирамга лаеклы.